**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«1»март 2020 ел № 61/2

ТР Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советының 2018 елның 9 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган мөлкәтне озак вакытка исәпләнгән нигездә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирү тәртибен раслау турында» 46/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 4.1 өлеше, «Кече һәм урта эшмәкәкрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советының 2018 елның 9 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган мөлкәтне озак вакытка исәпләнгән нигездә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирү тәртибен раслау турында» 46/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның исемендә һәм 1 пунктында «(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш)» сүзләренә алыштырырга;

1.2. әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган мөлкәтне озак вакытка

исәпләнгән нигездә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирү тәртибененең исемендә һәм 1.1 пунктында «(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш)» сүзләренә алыштырырга;

1.3. Тәртипнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 1.7 пунктчасын өстәргә:

«1.7. Әлеге Тәртипнең 2-3 пунктлары нигезләмәләре әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән җир кишәрлекләрен арендага бирү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагылмый.

Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән җир кишәрлекләрен арендага бирү тәртибе һәм шартлары граждан законнары һәм җир законнары нигезендә билгеләнә.»;

1.4. 3.4 пунктның беренче җөмләсендә «милек арендалаучы һәм» сүзләреннән соң «авыл хуҗалыгы кооперативлары булган яки» сүзләрен өстәргә;

1.5. 3.6 пунктында «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирелгән сүзләре алдыннан «яки авыл хуҗалыгы кооперативлары булган» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны Мәләкәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

В.И.Артемьев